КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 гыйнвар г.Казань № 20

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән расланган «2019 – 2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 –2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 сентябрь, 761 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 30 нчы; 2021 ел, 22 апрель, 273 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 59 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2019 – 2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – дәүләт программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

дәүләт программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>
Дәүләт программасын финанслау күләме түбәндәгечә тәшкил итәчәк:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Дәүләт программасы бюджеты</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 510,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 200,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>900,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>625,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 125,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 125,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>6 485,0</td></tr>
</table>
Шул исәптән дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы вәкаләтле органга бүлеп бирелде:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 510,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>1 200,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>900,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>625,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 125,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>1 125,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>6 485,0</td></tr>
</table>
Шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:<br>
(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>634,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>504,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>378,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>250,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>450,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>450,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 666,2</td></tr>
</table>
</td>
</tr>
</table>

<table>
<tr>
<td></td>
<td>Шулай ук Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү нигезендә күченеп килгән ватандашларга өстәмә гарантияләр һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасын түбәндәге күләмендә җәлеп итү күздә тотыла:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>875,8</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>696,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>522,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>375,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>675,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>675,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>3 818,8</td></tr>
</table>
Дәүләт программасын финанслау күләмнәренә ел саен төгәллек кертелергә мөмкин»;</td>
</tr>
</table>

дәүләт программасының I бүлегендәге «Татарстан Республикасы икътисады» бүлекчәсендә:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ИнноКам» үзәген үстерүгә Яр Чаллы моношәһәрендә алга китеп үсеш алган территория булдыру ярдәм итәчәк. Алга китеп үсеш алган территория төзү 10 мең яңа эш урыны булдырырга һәм 38,4 млрд.сум инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.»;

уникенче абзацта «АСИҮТ» сүзләрен «алга китеп үсеш алган территория» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «АСИҮТ» сүзләрен «алга китеп үсеш алган территория» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «АСИҮТ» сүзләрен «алга китеп үсеш алган территория» сүзләренә алмаштырырга;

дәүләт программасының IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Дәүләт программасын гамәлгә ашыруга
финанс ресурслары күләмнәре

Дәүләт программасының ресурслар белән тәэмин ителешенә түбәндәгеләр нигез була: Россия Федерациясе Президентының «Чит илдә яшәүче ватандашларның Россия Федерациясенә ирекле күчеп килүенә ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы, «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы, «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан

Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы, «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы, «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы, «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары.

2025 елга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Дәүләт программасын финанслау күләме түбәндәгечә тәшкил итәчәк:

(мең сум)

| Ел | Дәүләт программасы бюджеты |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 1 125,0 |
| 2024 | 1 125,0 |
| 2025 | - |
| Барлыгы | 6 485,0 |

Шул исәптән дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы вәкаләтле органга түбәндәгечә бүлеп бирелде:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 1 125,0 |
| 2024 | 1 125,0 |
| 2025 | - |
| Барлыгы | 6 485,0 |

Шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|
| 2019 | 634,2 |
| 2020 | 504,0 |

| | |
|---|---|
| 2021 | 378,0 |
| 2022 | 250,0 |
| 2023 | 450,0 |
| 2024 | 450,0 |
| 2025 | - |
| Барлыгы | 2 666,2 |

Шулай ук Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү нигезендә күченеп килгән ватандашларга өстәмә гарантияләр һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасын түбәндәге күләмендә җәлеп итү күздә тотыла:

(мең сум)

| Ел | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|
| 2019 | 875,8 |
| 2020 | 696,0 |
| 2021 | 522,0 |
| 2022 | 375,0 |
| 2023 | 675,0 |
| 2024 | 675,0 |
| 2025 | - |
| Барлыгы | 3 818,8 |

1. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.1 пунктында күрсәтелгән «Чит илдә яшәүче ватандашларга массакүләм мәгълүмат чаралары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, «Ватандашлар» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша дәүләт программасын тормышка ашыру турында мәгълүмат җиткерү, истәлекләр, буклетлар бастырып чыгару, «кайнар линия» телефоннары эшен оештыру. «Мәгълүматны актуаль хәлдә тоту» чараларын финанслау 337,2 мең сум күләмендә планлаштырылды.

2. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.2 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын беренчел торак белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү (6 ай дәвамында торакның аренда кыйммәтенең бер өлешен компенсацияләү)» чараларын финанслау 4 776,0 мең сум күләмендә планлаштырылды.

3. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 2.1 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча һөнәри белем бирүнең төп программалары һәм өстәмә һөнәри программалар буенча укыту» чараларын финанслау дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан 332,0 мең сум күләмендә планлаштырылды.

4. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.3 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина тикшерүен үткәрү һәм медицина ярдәме күрсәтү» чараларын финанслау 1 039,8 мең сум күләмендә планлаштырылды.

Дәүләт программасын финанслау күләмнәренә ел саен төгәллек кертелергә мөмкин.»;

дәүләт программасының 4 нче кушымтасында:

2.1 пунктның 16 графасында «46,7 РФБ 31,1 РТБ» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның «вәкаләтле орган тарафыннан, шул исәптән техник элемтә каналларын кулланып үткәрелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасы презентацияләре саны» юлындагы 16 графасында «47,8 РФБ 31,8 ТРБ» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктның 16 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«277,68 РФБ 185,12 ТРБ»;

3.3 пунктның «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы нигезендә түләү алмыйча күрсәтелә торган медицина ярдәменнән гарантияләнгән күләмдә файдаланган, шулай ук түләүле медицина хезмәтләреннән һәм башка хезмәтләрдән, шул исәптән адаптация чорында Татарстан Республикасында ирекле медицина иминияте шартнамәсе нигезендә файдаланган Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары саны, кеше» юлының 16 графасында «129,0 РФБ 86,0 ТРБ» сүзләрен «97,32 РФБ 64,88 ТРБ» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның 2 графасында «ТР СИФ» сүзләрен «ТР буенча РСФ» сүзләренә алмаштырырга;

«Дәүләт программасы буенча барысы, шул исәптән:» юлының 16 графасында «1125,0» саннарын «625,0» саннарына алмаштырырга;

«Россия Федерациясе бюджеты» юлының 16 графасында «675,0» саннарын «375,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлының 16 графасында «450,0» саннарын «250,0» саннарына алмаштырырга;

Россия Федерациясе Президентының 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы белән расланган «Чит илдә яшәүче ватандашларның Россия Федерациясенә ирекле күчеп килүенә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт программасында катнашучыларны Татарстан Республикасы территориясендә кабул итү регламентының 2.9 пунктындагы җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү, балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат (белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны тәртипкә сала торган норматив хокукый актларда каралган тәртиптә).»;

файдаланылган кыскартылмалар исемлегендә «ТР СИФ – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесе» сүзләрен «ТР РСФ – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Социаль иминият фонды атамасын, шул исәптән аның кыскартылган билгеләмәсен,

Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды итеп үзгәртү карала, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин